СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

№ 7-7 — «03» март 2016 ел

## 2016 елның 28 февралендә референдумда кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2015 елның 1 мартында референдум нәтиҗәләре нигезендә: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2016 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
Ишки торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау:
Нариманова урамы-400м

«Әйе» «Юк»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2016 елның 29 февралендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 32 номерлы карарын теркәргә.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану юнәлешләрен һәм күләмнәрен кушымта буенча билгеләргә.

3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе




/Ф.Г.Хабеев /

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының 3 март, 2016 ел, № 7-7 карарына
КУШЫМТА

Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану
юнәлешләре һәм күләмнәре

| N т/п | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең атамасы | Шул исәптән планлаштырылган чаралар | чараларны гамәлгә ашыруга акча күләме, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге ; | Ишки торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау: Нариманова урамы- 400м | 55,0 |
| Барлыгы | | | 55,0 |